# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Лебедино авыл җирлеге составына керүче Березовая Грива авылы

10 ноябрь 2019 ел.

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Лебедино авыл җирлеге составына керүче Березовая Грива торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Лебедино авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булмаган кешедән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- җирлек эчендәге юлларга вак таш җәю,төзекләндерү һәм караптоту;
  - техниканы карап тоту (тракторлар,УАЗ автомашиналары, янгын сүндерү автомашиналары, килешү буенча хезмәт хакы);
  - авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм килешү буенча хезмәт хакы түләү;
  -җирлек территориясен төзекләндерү (балалар мәйданчыгы территориясен койма белән әйләндереп алу һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булучыларга һәйкәл кую өчен төзелеш материаллары сатып алу, агач кисү, триммер сатып алу, килешү буенча хезмәт өчен түләү)

3. Әлеге карарны Лебедино авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Березовая Грива авылы, Пушкин урамы, 2Б, адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Лебедино авыл җирлеге башлыгы** **Ю.И. Тюкарев**